РАСЛЫЙМ
Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге директоры

______________З.З.ИБЛӘМИНОВА
«___» ________________ 2022 ел

**XXII «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»**
**ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕНЕҢ НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләр

1.1. Әлеге нигезләмә XXII «Иделем акчарлагы» яшь язучылар конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм уздыру, Конкурста катнашу һәм Конкурс җиңүчеләрен ачыклау тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге беренче тапкыр 2000 елның 1 сентябреннән татар телендә иҗат итүче яшь язучылар, шагыйрьләр, драматурглар өчен уздыра башлый. Ул традицион рәвештә ел саен уздырылып килә.

1.3. Конкурсны оештыручылар: Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе һәм Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Конкурсның максаты - талантлы яшь каләм ияләрен барлау, берләштерү, иҗатларын активлаштыру.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- яшь язучыларның иҗат мөмкинлекләрен арттыру, иҗади яктан үсәргә шартлар булдыру;
- иҗади һәм профессиональ бәйләнешләрне ныгыту;
- яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең игътибарын татар әдәбиятына юнәлтү һәм иҗатка кызыксыну уяту.

## 3. Конкурсны уздыру тәртибе һәм шартлары

3.1. Конкурста Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче, татар телендә иҗат итүче яшь каләм ияләре катнаша ала.

3.2. Катнашучыларның яше 14тән алып 30га кадәр.

3.3. Бәйге өч этапта үткәрелә:

**3.3.1. I этап – 2022 елның июленнән 30 нчы сентябренә кадәр** әдәби әсәрләрне кабул итү.

**3.3.2. II этап – 2022 елның 1 октябреннән 31 октябренә кадәр** сайлап алу туры. Жюри тарафыннан әдәби әсәрләрне тикшерү, бәяләү.

**3.3.3. III этап – 2022 елның ноябре -** йомгаклау өлеше: алдан төзелгән программа нигезендә, жюри тарафыннан әсәрләре уңай бәяләнгән конкурсантлар өчен иҗат мәктәбе оештыру.

3.4. Бәйге түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- поэзия;
- проза;
- драматургия;
- балалар әдәбияты (төрле жанрда: шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, фэнтези). Әлеге номинациядәге әсәрләр балалар аудиториясенә юнәлдерелгән булырга тиеш.

3.5. Бәйгенең беренче этабына әдәби әсәрләр idelem.akcharlagi@gmail.com электрон адресы буенча 2022 елның 30 сентябренә 23:59 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3.6. Бәйгегә әсәр җибәрү белән катнашучы аны бастыруга һәм интернет-ресурсларга урнаштыруга ризалык бирә. Оештыручылар, автор һәм әсәрнең исемен күрсәтеп, автор ризалыгыннан башка, бәйгегә килгән эшләрне куллану мөмкинлегенә ия була (катнашучы 3 нче турга үтсә, җыентыкта бастыру өчен һ.б.).

3.7. Әсәрләрне бәйгегә җибәргән очракта, катнашучы бәйге шартлары белән килешә.

## 4. Конкурс эшләренә таләпләр һәм бәя бирү тәртибе

4.1. Кыска күләмле әсәрләрнең (шигырь, нәсер, парча һ.б.) саны өчтән дә ким булмавы шарт.

4.2. Катнашучы, әсәрләре белән бергә, үзе турында кыскача мәгълүмат һәм заявка тутырып җибәрергә тиеш (Кушымта 1).

4.3. Әсәрләрне түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш: Times New Roman шрифтында, 12 нче кегль, 1,5 интервалда.

4.4. Бәйгедә автор үзе иҗат иткән әсәр белән генә катнаша ала.

4.5. Алдагы елларда Гран-прига ия булучылар катнаша алмый.

4.6. Бәйгедә бер үк әсәр белән икенче тапкыр катнашып булмый.

4.7. Югарыда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән әсәрләр бәйгедә каралмый.

4.8. Бәйгедә катнашучыларның әсәрләре мәртәбәле жюри тарафыннан бәяләнәчәк. Барлык номинацияләрдә дә беренче, икенче, өченче урыннар һәм Гран-прига лаек булучылар билгеләнә. Махсус һәм кызыксындыру бүләкләре дә каралган. Жюри хөкеме буенча, һәр номинациядә барлык призлы урыннар яки Гран-при билгеләнмәскә дә мөмкин.

4.9. Бәйгенең нәтиҗәләре буенча иң яхшы әсәрләр «Иделем акчарлагы» әдәби җыентыгында урын алачак.

4.10. Конкурс катнашучыларына электрон сертификат җибәрелә.

## 5. Жюри

5.1. Жюри рәисе һәм әгъзалары оештыручылар тарафыннан билгеләнә. Ел саен жюри әгъзаларының составы үзгәрергә мөмкин.

## 6. Элемтә өчен контактлар

Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 58 йорт, 307 офис)

Телефон: 231-81-54

E-mail: idelem.akcharlagi@gmail.com

Рәсми сайт: www.mc-idel.ru

Кушымта 1

# XXII «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»
## бәйгесендә катнашу өчен заявка

**Номинация:** ______________________

| | |
|---|---|
| Фамилияң /Исемең /Әтиеңнең исеме | |
| Туган көнең, ае, елы | |
| Өй адресың (**ИНДЕКС БЕЛӘН!**) | |
| Яшәү урыны | |
| Телефон номерың | |
| E-mail | |
| Паспорт,<br>туу таныклыгы<br>(серия, №, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән) | |
| ИНН | __ __________ |
| Иминият таныклыгы (Пенсионное страховое свидетельство) | ___-___-___-__ |
| Яраткан авторларың | |
| Яраткан китапларың | |
| Язучылар өчен булган тагын нинди бәйгедә катнашканың бар? | |
| «Иделем акчарлагы» конкурсының йомгаклау турына үткән очракта кем белән күрешергә телисең? | |

## *СОГЛАСИЕ ПРАВОВЛАДЕЛЬЦА*

**- С ПРАВИЛАМИ положения о конкурсе ознакомлен и согласен;**
**- СОГЛАСЕН на обработку оргкомитетом мероприятия указанных в ней персональных данных (в соответствии с требованиями федерального закона № 152-ФЗ от 27.07.2006 «О персональных данных»);**
**- СОГЛАСЕН, что оргкомитет конкурса не несет ответственности за претензии и иски, связанные с авторскими и смежными правами материалов, предоставляемых на конкурс;**
**- СОГЛАСЕН на передачу прав на дальнейшее использование работы или ее фрагментов в информационных, научных, учебных или культурных целях (публикация в сборнике конкурса, на сайте организации, СМИ и т.д.) без выплаты вознаграждения, но с обязательным указанием имени автора и источника заимствования (в соответствии с требования гражданского кодекса РФ (часть четвертая) № 230 - ФЗ от 18.12.2006 «Авторское право»);**
**- ПРИНИМАЮ ответственность за точность указанной выше информации.**

____________________________________________ *(Ф.И.О., подпись)*

*Дата:*